КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 924

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 11 июль, 566 нчы; 2019 ел, 24 сентябрь, 875 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасының «2019 – 2022 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» ярдәмче программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына каникуллар вакытында балаларның ялын оештыруны тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибе 1 нче ярдәмче программага $1^1$ нче кушымтада китерелгән.»;

$1^1$ нче кушымта өстәргә (карарга теркәлә).

2. 2020 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 ел, 31 март, 191 нче карарының 1 нче пунктындагы өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар, 2020 елга (2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына) бюджеттан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасының бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин